РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл җирлеге
Советы

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы, ул. Пионерская, 1

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы, Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karmalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www. karmalinskoe-sp.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 7 марты № 2

**Татарстан Республикасы**
**Түбән Кама муниципаль районының**
**«Кармалы авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге Уставына**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм авыл җирлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Кармалы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң игълан итәргә.
4. Әлеге карар законнарда каралган тәртиптә үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кармалы авыл җирлеге
башлыгы А.Д. Кубышкин

Кармалы авыл җирлеге Советының
2019 елның 7 мартындагы
2нче номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясында 1 пунктның 14 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларныҗыю (шул исәптән аерым җыю) һәмтранспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу».

2.«Җирлек җирле үзидарә органнарының Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары» 7 статьясында:

а) 1 пунктның 13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән мөгамәлә буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру;».

б) 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча белән тулыландырырга:

«16) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру».

3. «Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы» 8 статьясында 2 пунктта «ябык» сүзен «гавами булмаган» сүзләренә алмаштырырга.

4. «Җирлек башлыгы статусы» 41 статьясында 3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә,муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, профсоюзда катнашудан тыш, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешмада, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез милек милекчеләр ширкәтләрендә катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашудан тыш;муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү яки оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә,гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очраклар;».

5. «Башкарма комитет вәкаләтләре» 47 статьясында

а) 1 пунктның 6 пунктчасының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша».

б)1 пунктның 8 пунктчасының алтынчы абзацында түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә

«, муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында һәм мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыра».

в)1 пунктның 11 пунктчасының дүртенче абзацында «әлеге Уставның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктында каралган» сүзләрен«әлеге Уставның 6 статьясындагы 1 пунктының 4, 9, 18, 19 пунктчаларында каралган» сүзләренә алмаштырырга.

г) 2 пунктның 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән мөгамәлә буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру».

д) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру».

6. «Җирлек Уставының үз көченә керү тәртибе, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар» 84 статьясында:

а) 3 пунктта «җирле үзидарә органнары структурасы»сүзләреннән соң«Җирлек Советы депутатларының санлы составы»сүзләрен өстәргә.

б) 4 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Җирлек башлыгы кул куйган Җирлек Советы карары белән;».

в) 4 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Җирлек Советы тарафыннан кабул ителгән һәм Җирлек башлыгы кул куйган аерым норматив хокукый акт белән. Бу очракта әлеге хокукый актта кабул итү турындаҖирлек Советы карары реквизитлары куела. Җирлек Советының мондый карарынаҖирлек Уставына кертелә торганкүчмә нигезләмәләр һәм (яки)үзгәрешләр һәм өстәмәләрнең көченә керүе турында нормалар кертү рөхсәт ителми.

г) 5 пунктта тиешле килештәге «муниципаль берәмлек уставы» сүзтезмәсентиешле килештәге «Җирлек Уставы» сүзтезмәсенә алмаштырырга.